*Авылымда таңнар ямьле минем*
*Бәлки миңа шулай тоела*
*Туган авылым минем табигатьнең*
*Иң түренә кереп сыенган.*




Гүзәл Кама Тамагы районының көнбатыш ягында бер авыл урнашкан. Келәнче авылы. Ул авыл башка авыллардан берни белән дә аерылмый кебек, ә алай да шул авыл кызы булгач, аннан да кадерлерәк авыл юк. Аның чиста хавасы җанга дәва, челтерәп аккан чишмә сулары бөтен авыруны баса кебек. Һәр ел фасылы минем авылымда үзенчә матур. Кышын бөтен табигать ап-ак. Су буенда үсеп утыручы таллардагы бәсләрне җил акрын гына куып боз өстенә тошерә. Бозда исә балалар тимераякта шуалар. Салкын дип тә тормыйлар.





Язын авылыма “җан керә”. Карлар эреп беренче үләннәр чыга, агачлар яфрак яралар. Кошлар жырына кушылып жырлардай булып йорисен. Ә инде жәй башларында авылым гөрләтеп Сабан Туйларын уздыра. Ботен тирә-як авыллар жыела. Туганнар кайта. Жәй ул Сабан Туй гына түгел бит әле, бу вакытта бөтен авыл эштә инде, бакчадан кермибез дә. Бәбкәләр саклап көннәребез уза да китә. Жәй сизелми дә кала, авылыма алтын көзләр дә килә. Табигать акрын гына төсен үзгәртә. Ничектер күңелсез дә булып китә. Яңгырлары, салкын шомлы җилләре күңелгә моңсулык бирә. Авылымда әле бик әйбәт кешеләр дә яши. Бер-берсенә ярдәмләшеп яшиләр алар. Кыен вакытта да, сөенечтән шашып йөргәндә дә терәк була белә безнең авыл халкы. Авылымның шундый мәрхәмәтле кешеләре белән горурланып яшим. Авылымда берничә кибет, мәдәният йорты бар. Әллә каян балкып торган яңа биналы мәктәп тә күренә. Үзем дә шул мәктәптә белем



алам. Укытучыларыбыз да бик әйбәт кешеләр. Авыр ләкин мактаулы хезмәтләрен теләп башкаралар. Мәктәпкә көн саен теләп, сөенә-сөенә укырга йорибез.



Сүземне дәвам итеп кыскача үзем турында сөйләп китәсем килә. Мин Шангараева Адилә Данил кызы 2001 нче




елның 6 нчы июлендә туганмын. Хәзерге вакытты 4 нче сыйныфта белем алам. Җырларга, биергә ратканга бөтен конкурсларда да катнашып призлы урыннар яулыйм. Шигырь сөйләү конкурсында катнашып 2 нче урынны алдым. Мәктәптә утә торган чараларда бик теләп, актив катнашып барам. Район үзәгендә “Гаилә бәйрәме”ндә гаиләбез белән катнаштык. Мәктәптә гел “5” ле билгеләренә генә укыйм. “Вперед – в прошлое – 2012” конкурсы турында ишеткәч бик теләп катнашырга булдым. “Мое открытие” номинациясен сайлап, сыйныф җитәкчем Рәсимә Хәйретдин кызы белән үзебезнең авыл буйлап “сәяхәткә” чыктык. Үзебезнең эшнең нәтиҗәсе итеп презентация эшләдек. Быел гына уздырылган



район күләм олимпиадасында математика фәненнән призлы 2 нче урын алдым.

Ишмиева Рәсимә Хайретдин кызы 1968 нче елның 15 нче ноябрендә чаян йолдызлыгы астында туган. Хәзерге вакытта Келәнче



гомум белем бирү мәктәбендә башлангыч сыйныф укытучысы булып эшли. Эшләү стажы – 23 ел, укытучы-методист. Районда узган укытучылар белән бәйле булган конкурсларда актив катнаша. Чәчәкләр үстерергә ярата.

Нәҗмиева Рамилә Рафаэль кызы 1993 нче елның 3



нче июлендә туган. Хәзерге вакытта “Казан сәүдә-икътисад техникумы”нда 3 нче курста “Менеджмент” специальносте буенча укый. Математикадан районда узган конференцияда катнашып сертификат алды. Түбән Камада узган конференцияга барып дипломат булды. Техникум тормышында да актив катнаша. Төрле рәсем конкурсларында катнашып 1 нче урын ала.